КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 31 октябрь г.Казань № 943

«Демография» илкүләм проектының «Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм» федераль проекты кысаларында һөнәри укытуны һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру чараларында катнашучы гражданнарның йомгаклау аттестациясен үткәрү буенча аттестация (имтихан) комиссияләре составына кертелергә тиешле эш бирүчеләр һәм (яки) эш бирүчеләр берләшмәләре (иҗтимагый эшлекле оешмалар) вәкилен (вәкилләрен) билгеләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнарның аерым категорияләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру чараларын гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2024 елның 21 февралендәге 201 номерлы карары белән расланган Гражданнарның аерым категорияләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру чараларын гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәнең 5 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Демография» илкүләм проектының «Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм» федераль проекты кысаларында һөнәри укытуны һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру чараларында катнашучы гражданнарның йомгаклау аттестациясен үткәрү буенча аттестация (имтихан) комиссияләре составына кертелергә тиешле эш бирүчеләр һәм (яки) эш бирүчеләр берләшмәләре (иҗтимагый эшлекле оешмалар) вәкилен (вәкилләрен) билгеләү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Тәрҗемәче: А.М.Сәгыйтова

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 31 октябрь, 943 нче
карары белән расланды

«Демография» илкүләм проектының «Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм» федераль проекты кысаларында һөнәри укытуны һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру чараларында катнашучы гражданнарның йомгаклау аттестациясен үткәрү буенча аттестация (имтихан) комиссияләре составына кертелергә тиешле эш бирүчеләр һәм (яки) эш бирүчеләр берләшмәләре (иҗтимагый эшлекле оешмалар) вәкилен (вәкилләрен) билгеләү тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Демография» илкүләм проектының «Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм» федераль проекты кысаларында һөнәри укытуны һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру чараларында катнашучы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнарның аерым категорияләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру чараларын гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2024 елның 21 февралендәге 201 номерлы карары белән расланган Гражданнарның аерым категорияләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру чараларын гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәнең 9 пункты нигезендә сайлап алынган гражданнар тарафыннан белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда (алга таба – белем бирүче оешма) укучы гражданнарның йомгаклау аттестациясен үткәрү буенча аттестация (имтихан) комиссияләре (алга таба шул ук эзлеклелектә – укыту, йомгаклау аттестациясе, комиссия) составына кертелергә тиешле эш бирүчеләрнең һәм (яисә) эш бирүчеләр берләшмәләренең (иҗтимагый эшлекле оешмаларның) вәкилен (вәкилләрен) (алга таба – эш бирүчеләр вәкилләре) билгеләү тәртибен билгели.

2. Комиссияләр төзү максатларында белем бирү оешмасы, йомгаклау аттестациясен үткәрү датасына кадәр 15 эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Вәкаләтле орган) ведомство буйсынуындагы «Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенә (алга таба – халыкны эш белән тәэмин итү үзәге) комиссияләр составына һәр эш бирүче буенча кертү өчен эш бирүчеләр вәкилләре кандидатуралары буенча тәкъдимне (алга таба – кандидатуралар буенча тәкъдим) әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтадагы форма буенча шәхсән яисә почта элемтәсе аша яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең электрон почта адресы буенча җибәрелгән электрон документ ярдәмендә юллана.

3. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге кандидатуралар буенча тәкъдимнәр кергән көннән алып биш эш көне эчендә әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасындагы форма буенча комиссияләр составына кертелергә тиешле эш бирүчеләр вәкилләре исемлеген (алга таба – исемлек) төзи һәм карап тикшерү өчен исемлекне Вәкаләтле

органга җибәрә.

4. Вәкаләтле орган җитәкчесе яки ул вәкаләт биргән зат халыкны эш белән тәэмин итү үзәгеннән кергән көннән алып биш эш көне эчендә комиссияләр составына кертелергә тиешле эш бирүчеләр (эш бирүче) вәкилләре (вәкиле) исемлегенә кертелгәннәр арасыннан затны (затларны) билгеләү турында яки комиссияләр составына кертелергә тиешле эш бирүчеләр (эш бирүче) вәкилләре (вәкиле) исемлегенә кертелгәннәр арасыннан затны (затларны) билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карар турындагы мәгълүматны халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә ирештерә.

Эш бирүченең комиссия составына кертелергә тиешле вәкиле тарафыннан исемлеккә кертелгән затны билгеләүдән баш тарту турындагы карар Вәкаләтле орган тарафыннан кабул ителү өчен эш бирүченең «Россиядә эш» халыкны эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә бердәм цифрлы платформада исәпкә алу язуы булмау нигез булып тора.

5. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге әлеге Тәртипнең 4 пункты нигезендә Вәкаләтле орган тарафыннан кабул ителгән карар турында мәгълүмат кергән көннән алып ике эш көне эчендә белем бирү оешмасына аның кандидатуралар буенча тәкъдимен карап тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карар турында язма рәвештә хәбәр итә.

«Демография» илкүләм проектының «Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм» федераль проекты кысаларында һөнәри укытуны һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру чараларында катнашучы гражданнарның йомгаклау аттестациясен үткәрү буенча аттестация (имтихан) комиссияләре составына кертелергә тиешле эш бирүчеләр һәм (яисә) эш бирүчеләр берләшмәләре (иҗтимагый эшлекле оешмалар) вәкилен (вәкилләрен) билгеләү тәртибенә
1 нче кушымта

Форма

«Демография» илкүләм проектының «Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм» федераль проекты кысаларында һөнәри укытуны һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру чараларында катнашучы гражданнарның йомгаклау аттестациясен үткәрү буенча аттестация (имтихан) комиссияләре составына кертү өчен Татарстан Республикасының эш бирүчеләр һәм (яки) эш бирүчеләр берләшмәләре (иҗтимагый эшлекле оешмалар) вәкиле (вәкилләре) кандидатуралары буенча

______________________________________________________________

(белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма исеме)

ТӘКЪДИМЕ

| Т/с | Уку буенча чараларда катнашучы турында мәгълүмат | | Эш бирүче вәкиле турында мәгълүмат | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | «Россиядә эш» бердәм цифрлы платформада гражданның гариза номеры* | граждан укый торган белем бирү программасының исеме | эш бирүченең тулы исеме | эш бирүченең ИННы | эш бирүче вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | эш бирүче вәкиленең били торган вазыйфасы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

* «Россиядә эш» халыкны эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә бердәм цифрлы платформа.

_____________________________________ /____________/_______________________________

(белем бирү оешмасы җитәкчесе вазыйфасының исеме) (имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

20___ ел, «_____»____________

Тәрҗемәче: А.М.Сәгыйтова

«Демография» илкүләм проектының «Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм» федераль проекты кысаларында һөнәри укытуны һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру чараларында катнашучы гражданнарның йомгаклау аттестациясен үткәрү буенча аттестация (имтихан) комиссияләре составына кертелергә тиешле эш бирүчеләр һәм (яисә) эш бирүчеләр берләшмәләре (иҗтимагый эшлекле оешмалар) вәкилен (вәкилләрен) билгеләү тәртибенә
2 нче кушымта

Форма

______________________________________________________________ның (нең)
(белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма исеме)

«Демография» илкүләм проектының «Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм» федераль проекты кысаларында һөнәри укытуны һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру чараларында катнашучы гражданнарның йомгаклау аттестациясен үткәрү буенча аттестация (имтихан) комиссияләре составына кертелергә тиешле Татарстан Республикасы эш бирүчеләр һәм (яки) эш бирүчеләр берләшмәләре (иҗтимагый эшлекле оешмалар) вәкиле (вәкилләре) кандидатуралары исемлеге

| Т/с | Белем бирү оешмасының исеме | Эш бирүче вәкиле турында мәгълүмат | | | | «Россиядә эш» бердәм цифрлы платформада эш бирүченең исәпкә алу язуы булу яки булмавы турында мәгълүмат*, 1 – бар, 0 – юк |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | эш бирүченең исеме | эш бирүченең ИННы | эш бирүче вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | эш бирүче вәкиленең били торган вазыйфасы | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

* «Россиядә эш» халыкны эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә бердәм цифрлы платформа.

«Татарстан Республикасының
Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге»
дәүләт казна учреждениесе
директоры ________________/______________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

20___ ел, «_____»____________

________________________